СОВЕТ КИЛЬДЕЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КИЛДИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

РЕШЕНИЕ — КАРАР

28.05.2019 — с. Кильдеево — 56-269

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Башлыгы В.М.Бурдин мәгълүматын тыңлаганнан соң, Килди авыл җирлеге Советы тарафыннан хупланган «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты эшләнгән, җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерелгән һәм җирлек халкы белән фикер алышу өчен кирәкле барлык процедуралар да үткәрелгән, дип билгеләп үтә. Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында 2003 елның 6 октябрендәге 131 - ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставының 18, 86-88 статьялары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге
карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставына № 1 кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Килди авыл җирлеге Уставы статьяларының яңа редакциясен расларга.
3. Әлеге карарны законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.
4. Әлеге карар гамәлдәге законнарда билгеләнгән срокларда үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге Башлыгы — В.М.Бурдин

Килди авыл җирлеге
Советының 28.05.2019 елгы
56-269 карарына
1 нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге Уставына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1.2. Килди авыл җирлеге Уставының 6 статьясының 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) җирлек территориясендә яшәүче хуҗасыз хайваннар белән мөрәҗәгать итү буенча эшчәнлек алып бару».

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы
Килди авыл җирлеге
Башлыгы В.М.Бурдин